ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

---

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

6 июнь 2024 ел №2-48

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 21 июлендәге 4-43 номерлы ТР Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советының карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Буа шәһәр Советы карар кабул итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 21 июлендәге 4-43 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы карарына (25.02.2020 №1-53, 24.06.2020 № 4-58, 30.10.2020 №1-2, 30.12.2022 №1-27 номерлы карарлар редак.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяда:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,201% шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләре;»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралганча, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки бакчачылык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,201%»;».

3, 4, 5, 6 нчы пунктларда «кадастр бәясеннән» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

1.2. 4 статьяда

1.2 пунктчасында «салым чоры тәмамланганнан соң киләсе елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча» сүзенең 1 пунктын алып ташларга;

2 нче пункт үз көчен югалткан дип танула.

1.3. 5 статьяны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«Салымны салым түләүче оешмалар салым чоры тәмамланганнан соң 28 февральдән дә соңга калмыйча түләргә тиеш. Салым буенча аванс түләүләр салым түләүче-оешмалар тарафыннан хисап чоры тәмамланганнан соң айның 28 нче көненнән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Салымны салым түләүче физик затлар салым чоры тәмамланганнан соң киләсе елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләргә тиеш.».

1.4. 7 статья үз көчен югалткан дип танырга.

1.5.8 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 3 пункт белән тулыландырырга: «3. Әлеге карарның 4 статяның 1 пунктчасының 1.4 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023-2024 елгы салым чорларында җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р. Р. Камартдинов